ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

26 май 2023г.

**КАРАР**

№ 4328

Шәһәр бюджеты акчаларын казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясының 5 пункты, 242.26 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда, Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары тарафыннан акчаларны казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 1 декабрендге 2155 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр бюджеты акчаларын казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 26 маендагы
4328 номерлы карарына
кушымта

Шәһәр бюджеты акчаларын казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясы нигезендә билгеләнгән, казначылык аша үткәрүдә катнашучыларга шәһәр бюджетыннан бирелә торган акчаларны (алга таба – максатчан акчалар) казначылык аша үткәрүне гамәлгә ашыру тәртибен түбәндәгеләр нигезендә билгели:

- товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында муниципаль контрактлар (алга таба – муниципаль контрактлар);

- субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр), Россия Федерациясе Бюджет кодексының 80 статьясы нигезендә бюджет инвестицияләре бирү турында шартнамәләр;

- юридик затларның (аларның бүлендек җәмгыятьләренең) устав (җыелма) капиталларына (мөлкәткә кертемнәренә) взнослар бирү турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә), аларның үтәлешен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре тора;

- товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында контрактлар (шартнамәләр), аларның үтәлешен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән муниципаль контрактларны, шартнамәләрне (килешүләрне) (алга таба – контракт (шартнамә) үтәү кысаларында бирелгән акчалар тора;

- концессион килешүләр, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр.

2. Федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында билгеләнгән очракларда, казначылык аша үткәрүдә катнашучылар ала торган (алган) максатчан акчалар (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.27 статьясындагы 1 пунктчаның дүртенче абзацында күрсәтелгән акчаларны да кертеп) казначылык аша үткәрелергә тиеш.

3. Әлеге тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль контрактларда, шартнамәләрдә (килешүләрдә), контрактларда (шартнамәләрдә) шул исәптән түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) казначылык аша үткәрүдә катнашучыларның акчалары белән операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен, казначылык аша үткәрүдә катнашучылар тарафыннан Федераль казначылыкта шәхси счетлар ачу турында;

2) Федераль казначылыкка әлеге тәртиптә билгеләнгән документларны тапшыру турында;

3) контрактларда (шартнамәләрдә), боерыкларда, шулай ук документларда муниципаль контракт, субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр), Россия Федерациясе Бюджет кодексының 80 статьясы нигезендә бюджет инвестицияләре бирү турында шартнамәләр идентификаторын күрсәтү турында.

4. Акчаларны казначылык аша үткәрү, Башкарма комитет белән төзелгән килешү нигезендә аның тарафыннан шәһәр бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашырганда, Федераль казначылыкның территориаль бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Казначылык аша үткәргәндә Федераль казначылыкның территориаль бүлекчәсе, бюджет акчаларын алучы һәм казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучы арасында документлар алмашу электрон имза кулланып гамәлгә ашырыла. Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны үз эченә алган документлар белән алмашкан очракта, шулай ук

казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучыда электрон имза кулланып мәгълүмат алмашуның техник мөмкинлеге булмаган очракта, документлар әйләнеше, документларны бер үк вакытта электрон йөрткечтә тапшырып, кәгазь чыганакта гамәлгә ашырыла.

6. Федераль казначылыкның территориаль бүлеге әлеге тәртипнең 4 пунктында каралган килешү нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.13-1 статьясы нигезендә шәхси счетлар ачканда һәм операцияләрне гамәлгә ашырганда бюджет мониторингы;

2) санкцияләгәннән соң шәхси счетлардагы максатчан акчалар белән операцияләр;

3) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясында күрсәтелгән акчаларны казначылык аша үткәрү.

7. Казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучылар, операцияләр гамәлгә ашырыла торган шәхси счетны (шәхси счет режимын) алып барганда һәм файдаланганда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән шартлар үтәлешен тәэмин итәләр.

8. Шәхси счетларда чагылдырылган максатчан акчалар белән операцияләр Башкарма комитетының финанс идарәсе тарафыннан чыгымнарны санкцияләү гамәлгә ашырылганнан соң үткәрелә.

9. Башкарма комитетның финанс идарәсе:

1) көн саен (эш көннәрендә) «Электрон бюджет» системасын мәгълүмати-аналитик тәэмин итүнең ярдәмче системасына муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) турында, шәхси счетлар турында һәм, Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, шәхси счетларда чагылдырылган максатчан акчаларны исәпләү һәм исәптән чыгару буенча операцияләр турында мәгълүмат бирә;

2) максатчан акчалар керү чыганакларын, максатчан акчаларны сарыф итү юнәлешләрен һәм максатчан чыгымнарны санкцияләү өчен кирәкле башка күрсәткечләрне үз эченә алган максатчан акчалар белән операцияләр турында, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматларны формалаштыру, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучылар тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар нигезендә, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып максатчан акчалар торган чыгымнарны санкцияләүне гамәлгә ашыра;

3) казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучы тарафыннан тапшырылган казначылык түләвен башкару турында боерыкларны тикшерүне 3 эш көне эчендә гамәлгә ашыра, шул исәптән түбәндәгеләрне тикшерү предметына:

- муниципаль контракт, шартнамә (килешү) идентификаторының туры килүе;

- муниципаль контрактта, шартнамәдә (килешүдә), контрактта (килешүдә), документларда күрсәтелгән идентификаторга туры килү;

- казначылык түләүләрен башкару турында боерыкта күрсәтелгән салым түләүченең исеме, идентификация номеры, исәпкә куелу сәбәбенең коды, акчаларны алучының банк реквизитлары, контрактта (шартнамәдә) һәм нигез-документларда күрсәтелгән салым түләүченең исеменә, идентификация номерына, исәпкә куелу сәбәбе кодына, акчаларны алучының банк реквизитларына туры килү;

- казначылык түләүләрен башкару турында боерыкта күрсәтелгән сумма максатчан акчаларны тиешле юнәлеш буенча тотудан калган акчалар суммасыннан һәм тиешле муниципаль контракт, шартнамә (килешү), контракт (шартнамә) буенча шәхси счетта калган акчалар суммасыннан артып китмәү;

- товарлар кайтаруга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле казначылык түләүләрен башкару турында боерыкта контракт (шартнамә) (номер, дата), нигез-документлар (номер, дата, тип) реквизитлары булу һәм аларның казначылык түләүләрен башкару турында боерык белән бергә тапшырылган контракт (шартнамә), нигез-документлар реквизитларына туры килүе;

- нигез-документтан чыгып, товарлар кайтаруга (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнар буенча операциянең эчтәлеге казначылык түләүләрен башкару

турындагы боерыкта күрсәтелгән түләүнең текстлы билгеләнешенә, муниципаль контракт, шартнамә (килешү), контракт (шартнамә) предметына (нәтиҗәләренә) һәм шартларына туры килү;

- казначылык түләүләрен башкару турында боерыкта күрсәтелгән түләүнең текстлы билгеләнеше максатчан акчаларны тоту юнәлешенә туры килү;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясының 3 пунктында каралган максатчан акчаларны шәхси счеттан күчерүгә тыюларны үтәү;

4) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.24 статьясының 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән очракларда, казначылык аша киңәйтеп үткәрелергә тиешле максатчан акчаларга карата тикшерүләр үткәрә.

10. Максатчан чыгымнарны санкцияләү өчен, казначылык аша үткәрүдә муниципаль катнашучылар Башкарма комитетның финанс идарәсенә тапшыралар:

1) муниципаль контракт;

2) шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) һәм акча йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документлар (алга таба - нигез-документлар).

11. Башкарма комитетның финанс идарәсе 10 эш көне эчендә, түбәндәге нигезләр буенча казначылык түләүләрен башкару турында боерыкларны кире кайтаруны гамәлгә ашыра:

1) әлеге тәртипнең 9 пунктының 3 пунктчасы нигезендә, тикшерү нәтиҗәләре буенча туры килмәү ачыклану;

2) әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган документлар тапшырылмау.

12. Шәхси счетта операцияләрне гамәлгә ашыруны тыю һәм баш тарту нигезләре Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.13-1 статьясының 10 һәм 11 пунктларында тиешенчә күрсәтелгән.

Шәхси счеттагы операцияләр Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.13-1 статьясының 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.13-1 статьясының 1 пунктында каралган тәртиптә туктатыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева